2019 ел, СЕНТЯБРЬ

кил□ ч□кне яктырта

# Яшьлек








# "Белем көне - белем бәйрәме"

"Белем көне - белем бәйрәме"



**2019/2020 уку елы**

1 а сыйныфы—22
1б сыйныфы—21
2 нче сыйныф—24
3 нче сыйныф—19
4 нче сыйныф—27
5 нче сыйныф—21
6 нчы сыйныф—26
7 нче сыйныф—25
8 нче сыйныф—26
9 нчы сыйныф—28
10 нчы сыйныф—9
11 нче сыйныф—14
Барлыгы: 263



**1 СЕНТЯБРЬ** – Белем бәйрәме килеп тә җитте. Бу көнне мәктәп безне үзенең ишекләрен киң ачып каршы алды. Беренче тапкыр мәктәпкә баручы да, өлкән сыйныфларда укучылар да - һәрберебез дулкынланып, шатланып каршы алды бу көнне. Быел гимназиябезгә беренче сыйныфка 59 бала аяк басты. Мәктәп тарихында беренче тапкыр 1 нче сыйныф укучыларын 2 төркемгә бүлделәр. Нәтиҗәдә, укытучылар коллективы да артты: Сәлимова Гөлшат Илсаф кызы 1б сыйныфын укыта башлады.



Гимназия барлыгы 263 укучыга Белем ишекләрен ачты.

Тантаналы линейкага мәртәбәле кунаклар - район Советы аппараты җитәкчесе Роза Сәлдәева, район ветераннар советыннан ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Лениза Якиева һ.б. лар килгән иде. Алар укучыларны, укытучыларны, ата-аналарны яңа уку елы башлану белән котладылар, укучыларга иҗади уңышлар, яхшы билгеләр, күңелле чаралар теләделәр. Сабир Өметбаев исемендәге яшь театр артистлары матур чыгышлары белән бәйрәмне бизәде. Беренче сыйныф укучылары уку елы башлануга аеруча шат, быел алар - 44. Аларны алда күпме яңа ачышлар, шатлыклы мизгелләр көтә! Әти-әниләр дә дулкынлана.

Аеруча беренче сыйныфка килгән балаларның кәефләре күтәренке. Аларны алда никадәр яңалык, ачышлар көтә.



Язилә Мусина

# Атна шәхесе - Рәүф




**Бу айның атна шәхесе - спортчы, нәфис сүз остасы, креатив, уңган егет Рәүф Шакиров! Ул гимназиябездә 11 нче сыйныфта белем ала. Аны бездә Г.Тукайга да, М. Җәлилгә дә охшаталар.**

**Туган көне:** 31.10.2002
**Яраткан фильм:** “1+1»; “2+1»; «В метре друг от друга»
**Яраткан ризык:** мәктәптә пешергән бәрәнге белән тавык.
**Яраткан спорт төре**: баскетбол
**Кызыксынулары:** театр, баскетбол

- **Сәлам, Рәүф!**
- Привет.
- **Синең кумирың бармы?**
- Кумир, хм... Әлбәттә, бар.
- **Син үзеңне уңышлы кеше дип санныйсыңмы?**
- Әйе, мин бик уңышлы.
- **Синен очен бәхет нәрсә ул?**
- Хм… бәхет минем өчен… ул, сәхнәдә чыгыш ясау, дуслар белән кәеф ачу.
- **Әгәр “вакыт машинасы”на утырып үткәнгә кайтып булса, син ни дә булса үзгәртер идеңме?**
- Юк, миңа барысы да ошый. Мин бернәрсәне дә үзгәртмәс идем.
- **11 нче сыйныф укучысы булуга карамастан, син бик актив тормыш алып барасың. Ничек өлгерәсең? Серен ач әле.**
- Һичшиксез, 11 нче сыйныфта бик авыр, чөнки безнең имтихан тапшырасы бар. Шуңа күрә без ел буе әзерләнәбез, бөтен көчебез укуга китә. Шуңа да карамастан минем өчен актив булу, сәхнәдә чыгыш ясау, җырлап -биеп йөрү - барысы да миңа көч бирә. Менә шулай энергия туплыйм да нык итеп укырга тотынам.
- **«Сәләт» турында сөйләп кит: ошадымы? Барырга буламы?**
- «Сәләт…» «Сәләт» - ул минем өчен икенче өй. Анда минем яраткан, якын дусларым. «Сәләт» - ул үзе бер дөнья.
- **Киләчәктә кем булырга уйлыйсың?**
- Мин үземне киләчәктә актер буларак күрәм. Театр сәхнәләрендә, кинолденталарда уңышлы чыгыш ясармын дип уйлыйм.
- **Уңышлар сиңа!**


gimnaziya_official
gimnaziya_official
1941
945
gimnaziya_official
gimnaziya_official
г. Мензелинск, респ. Татарстан
1 сентябрь
Яңа уку елы белән!
gimnaziya_official
gimnaziya_official
ГИМНАЗИЯ


gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
21 СЕНТЯБРЬ –
ХАЛЫКАРА ТЫНЫЧЛЫК КӨНЕ
gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official

# Туган көннәр



**Укытучылар:**
**Нуриева Гүзәл (22.09)**
**1нче а сыйныфы:**
**Сафиев  Әмир  (05.09)**
**Солтангалиев  Райнур (19.09)**
**1нче б сыйныфы:**
**Липин Булат  (05.09)**
**Хәертдинова Азалия (19.09)**
**2 нче сыйныф:**
**Николаева Азалия (12.09)**
**3 нче сыйныф:**
**Зиатдинова Азалия (15.09)**
**Нигъмәтуллина Самира (15.09)**
**4 нче сыйныф:**
**Армянинов Ждан (21.09)**
**5 нче сыйныф:**
**Степанова Елизавета (27.09)**
**Мөбарәкҗанов Вилдан (02.09)**
**6 нче сыйныф:**
**Латыпов Данил (11.09)**
**Миннәхмәтова Ралина (18.09)**
**Петров Рифат (17.09)**
**9 нче сыйныф:**
**Васильев Ратмир (16.09)**
**Иванов Владислав (21.09)**
**Нуруллина Айсылу (14.09)**
**11 нче сыйныф:**
**Минаев Айзат (15.09)**
**Сәхәбетдинова Регина (08.09)**








**Баш мөхәррир** - Крашева Рузалина
**Контент-мөхәррир**  - Маликова Камилә
**Әдәби консультантлар -** Гарипова Рузиля, Мусина Язилә
**Бүлек мөхәррирләре** - Авзалтдинова Камилә, Мулләхмәтова Айзилә
**Фотохәбәрче -** Яковлева Алсу
**Проект житәкчеләре** - татар теле һәм әдәбияты укытучылары Галиева Лилия Альберт  кызы, Ильина Миләүшә Әхтәм кызы, Заһрие-ва Гөлнара Рөстәм кызы.



423700, ТР, Минзәлә шәһәре,
Чаллы тракты, 1А,
тел./факс (885555)3-51-71,
www.gimnazia-menz.edusite.ru
e-mail: sch1104_tg@mail.ru
Instagram: @gimnaziya__official
http://vk.com/id324010745